РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ САБИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

САБА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

02.07.2026 №701-п

Татарстан Республикасы Саба муниципаль районында мәдәни-массакүләм чараларны матди тәэмин итү һәм мәдәни-массакүләм чараларда катнашучыларны тукландыру белән тәэмин итү тәртибен раслау турында

Мәдәни-массакүләм чараларны матди яктан тәэмин итүгә акчалардан нәтиҗәле файдалану, мәдәни-массакүләм чараларда катнашучыларны тукландыру белән тәэмин итү максатларында Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Саба муниципаль районында мәдәни-массакүләм чараларны матди тәэмин итү һәм мәдәни-массакүләм чараларда катнашучыларны тукландыру белән тәэмин итү тәртибен расларга (кушымта итеп бирелә).

2. Үз көчен югалткан дип танырга:

«Татарстан Республикасы Саба муниципаль районында мәдәни-массакүләм чараларны матди яктан тәэмин итү һәм мәдәни-массакүләм чараларда катнашучыларны тукландыру белән тәэмин итү тәртибен раслау турында» Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы башкарма комитетының 2015 елның 04 апрелендәге 527-п номерлы карарын;

-Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Башкарма комитетының 2016 елның 18 февралендәге 184-п номерлы «Саба муниципаль районы Башкарма комитетының 2015 елның 4 апрелендәге №527-па номерлы карарына үзгәреш кертү турында» карарын.

3. Әлеге карарның гамәлдә булуы 2026 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла дип билгеләргә.

4. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасының Хокукый мәгълүматлар турындагы http://pravo.tatarstan.ru.рәсми порталында бастырып чыгарырга.

Җитәкче М.Р.Кәримов

Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Башкарма комитетының
«___» _________ 20
________________карары белән
РАСЛАНДЫ

**Татарстан Республикасы Саба муниципаль районында мәдәни-массакүләм чараларны матди яктан тәэмин итү һәм мәдәни-массакүләм чараларда катнашучыларны тукландыру белән тәэмин итү тәртибе**

## 1. Гомуми нигезләмәләр

**1.1** Әлеге Тәртипнең максаты - мәдәни-массакүләм чараларны матди яктан тәэмин итү һәм Татарстан Республикасы Саба муниципаль районында мәдәни-массакүләм чараларда катнашучыларны тукландыру белән тәэмин итү (алга таба - Тәртип) Саба муниципаль районының мәдәни-массакүләм чараларга һәм мәдәни-массакүләм чаралар уздыручы муниципаль учреждениеләре тарафыннан акчаларны тотуны җайга салу.

**1.2** Мәдәни-массакүләм чараларга район, республика һәм Бөтенроссия мәдәни-массакүләм чараларның бердәм календарь планында каралган Фестивальләр, Конкурслар, смотрлар һәм башка мәдәни-массакүләм чаралар керә.

**1.3** Мәдәни-массакүләм чараларда катнашучыларны матди тәэмин итү нормаларына түбәндәгеләр керә: мәдәни-массакүләм чаралар уздыру көннәрендә катнашучыларны туклану белән тәэмин итү чыгымнары нормалары, истәлекле призлар чыгымнары нормалары; транспорт чыгымнары; почта-типография һәм канцелярия чыгымнары; торак урынны наемга түләү; мәдәни-массакүләм чараларда катнашучыларны матди тәэмин итүнең башка төрләре.

**1.4** Мәдәни-массакүләм чараларда катнашучыларга үзешчән сәнгатьтә катнашучылар, мәдәният учреждениеләренең клуб формированиеләрендә катнашучылар, иҗат коллективлары җитәкчеләре һәм вәкилләре, мәдәни-массакүләм чаралар турындагы кагыйдәләрдә, нигезләмәләрдә һәм регламентлаучы документларда килешенгән белгечләр керә.

**1.5** Катнашучыларны мәдәни-массакүләм чараларга җибәрү мәдәни-массакүләм чаралар уздыручы оешмаларның рәсми чакыруы нигезендә гамәлгә ашырыла.

## 2. Мәдәни-массакүләм чаралар уздырганда акчаларны тоту тәртибе

**2.1** Мәдәни-массакүләм чаралар уздырганда мәдәни-массакүләм чаралар уздыручы оешма тарафыннан раслана:

– мәдәни-массакүләм чаралар уздыру тәртибен җайга сала торган мәдәни-массакүләм чаралар турында нигезләмәләр, мәдәни-массакүләм чаралар программалары;

– мәдәни-массакүләм чараларда катнашучыларның Сан составын, аларны үткәрү срокларын һәм матди тәэмин итү нормаларын үз эченә алган сметалар.

**2.2** Мәдәни-массакүләм чаралар уздырылган көннәрдә катнашучыларны туклану белән тәэмин итү, мәдәни-массакүләм чараларда җиңүчеләрне һәм призерларны бүләкләү өчен истәлекле бүләкләр алу чыгымнары әлеге Тәртипнең 4 һәм 5 пунктлары нигезендә нормалар нигезендә башкарыла.

**2.3** Кунакханәләрдә урыннарны броньлау мәдәни-массакүләм чараларда катнашучыларның билгеләнгән вакытка кадәр бер тәүлектән дә соңга калмыйча башкарыла.

**2.4** Чараларда катнашучыларга бирелә торган торак урынны наемлау чыгымнары бер кешегә яшәүнең тиешле документлар белән расланган факттагы хакы буенча башкарыла, әмма әлеге Тәртипнең 4 пунктында билгеләнгән чикләрдә күбрәк түгел.

**2.5** Транспорт, телеграф, почта-типография, канцелярия һәм башка чыгымнар тармакта гамәлдә булган бәяләр яисә шартнамә бәяләре буенча мәдәни-массакүләм чараларны аеруча экономияле үткәрүне һәм чаралардан рациональ файдалануны тәэмин итә торган күләмнәрдә башкарыла.

## 3. Мәдәни-массакүләм чараларны финанслау тәртибе

**3.1** Мәдәни-массакүләм чараларны финанслау чыганаклары булып бюджет һәм бюджеттан тыш акчалар тора. Бюджеттан тыш акчалар хәйрия ярдәме, ирекле иганәләр һәм башка чыганаклар исәбеннән барлыкка килергә мөмкин.

**3.2** Мәдәни-массакүләм чараларны Матди тәэмин итү чыгымнары әлеге карар белән расланган нормалар нигезендә финанс-хуҗалык эшчәнлегенең расланган планы нигезендә булган акчалар чикләрендә тиешле финанслау чыганаклары исәбеннән башкарыла.

**3.3** Саба муниципаль районы территориясендә Саба муниципаль районының район бюджеты акчалары исәбеннән финанслана торган мәдәни-массакүләм чаралар үткәргәндә финанс белән тәэмин итү шартлары Саба муниципаль районы Башкарма комитеты тарафыннан расланган әлеге чаралар турындагы нигезләмәләрдә (регламентларда) билгеләнә.

## 4. Мәдәни-массакүләм чаралар уздырганда катнашучыларны һәм коллектив җитәкчеләрен туклану һәм яшәү белән тәэмин итү чыгымнары нормалары

| № | Чыгым исеме | Көнгә бер кешегә чыгымнар нормалары (сумнарда) |
|---|---|---|
| 1 | Саба районы территориясендә туклану өчен түләү | 300 |
| | ТР территориясендә туклану өчен түләү | 500 |
| | РФ территориясендә туклану өчен компенсация | 1000 |
| 2 | ТР территориясендә яшәү | 2000 гә кадәр |
| | ТР чикләреннән тыш, РФ дә яшәү | 3000 гә кадәр |
| | РФ чикләреннән тыш яшәү | 5000 гә кадәр |
| 3 | Чара үткәргәндә тукылануны оештыруга | 1000 гә кадәр |

Искәрмә: мәдәни-массакүләм чаралар уздырыла торган урыннарда акчасыз исәп-хисаплар буенча оешкан туклану белән тәэмин итү мөмкинлекләре булмаганда мәдәни-массакүләм чараларда катнашучыларга ведомость буенча югарыда күрсәтелгән нормалар буенча кулдан акча бирү рөхсәт ителә.

## 5. Мәдәни-массакүләм чараларда җиңүчеләрне һәм призерларны бүләкләү өчен акчалата бүләкләр һәм бүләкләр бәясе күләме

| Мәдәни-массакүләм чараларның исеме | Яуланган урын | Акчалата бүләкләр һәм бүләкләр бәясе(сумнарда) | |
|---|---|---|---|
| | | коллективлар (бер катнашучыга исәпләп) | шәхси |

| | | | |
|---|---|---|---|
| Республика конкурслары, смотрлар, фестивальләр. | I | 500 гә кадәр | 1500 гә кадәр |
| | II | 400 гә кадәр | 1000 гә кадәр |
| | III | 300 гә кадәр | 800 гә кадәр |
| Республика конкурслары, смотрлар, фестивальләр. | I | 1000 гә кадәр | 2000 гә кадәр |
| | II | 800 гә кадәр | 1500 гә кадәр |
| | III | 500 гә кадәр | 1000 гә кадәр |
| Бөтенроссия конкурслары, смотрлар, фестивальләр. | I | 1500 гә кадәр | 2500 гә кадәр |
| | II | 1000 гә кадәр | 2000 гә кадәр |
| | III | 800 гә кадәр | 1500гә кадәр |
| Төбәкара конкурслар, смотрлар, фестивальләр. | I | 1500 гә кадәр | 2500 гә кадәр |
| | II | 1000 гә кадәр | 2000 гә кадәр |
| | III | 800 гә кадәр | 1500гә кадәр |
| Халыкара конкурслар, смотрлар, фестивальләр. | I | 2000 гә кадәр | 3000 гә кадәр |
| | II | 1500 гә кадәр | 2500 гә кадәр |
| | III | 1000 гә кадәр | 2000 гә кадәр |
| Республика конкурсларына, смотрларга, фестивальләргә әзерләгән хореография, вокал, фольклор, инструменталь, театр коллективлары, нәфис сүз, сәнгать-эстетик юнәлеш җитәкчеләре. | I | 3000 гә кадәр | |
| | II | 2000 гә кадәр | |
| | III | 1000 гә кадәр | |
| Бөтенроссия конкурсларына, смотрларга, фестивальләргә әзерләгән хореография, вокал, фольклор, инструменталь, театр коллективлары, нәфис сүз, сәнгать-эстетик юнәлеш җитәкчеләре. | I | 4000 гә кадәр | |
| | II | 3000 гә кадәр | |
| | III | 2000 гә кадәр | |
| Төбәкара конкурсларга, смотрларга, фестивальләргә әзерләгән хореография, вокал, | I | 4000 гә кадәр | |

| | | |
|---|---|---|
| фольклор, инструменталь, театр коллективлары, нәфис сүз, сәнгать-эстетик юнәлеш җитәкчеләре. | II | 3000 гә кадәр |
| | III | 2000 гә кадәр |
| Халыкара конкурсларга, смотрларга, фестивальләргә әзерләгән хореография, вокал, фольклор, инструменталь, театр коллективлары, нәфис сүз, сәнгать-эстетик юнәлеш җитәкчеләре; | I | 5000 гә кадәр |
| | II | 4000 гә кадәр |
| | III | 3000 гә кадәр |

Искәрмә:

югарыда күрсәтелгән нормалар чикләрендә шәхси (истәлекле) призлар яисә кулдан акча белән бүләкләү рөхсәт ителә;

б) мәдәни-массакүләм чараларны оештыручылар бүләкләрнең башка бәясен, шулай ук мәдәни-массакүләм чараларда иң яхшы катнашучылар өчен махсус бүләкләрне хәйрия ярдәме, ихтыяри иганәләр, гариза кертемнәре һәм бюджеттан тыш финанслауның башка чыганаклары исәбеннән билгеләргә хокуклы.